Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Советының егерме тугызынчы утырышы

Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

15 декабрь, 2023 ел № 83

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 38 номерлы карары (Советның 2023 елның 31 мартындагы 64 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 78 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән туктатырга:

- «Чит ил валютасында муниципаль гарантияләр программасы» 18.1 статьясындагы 3 пунктын;

«Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программасы» 18.2 маддәсенең 3 пунктын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Хөсәенов